РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА
города Азнакаево Азнакаевского
муниципаль районы

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай
муниципаль районы
Азнакай шәһәре
БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 22 й., Азнакай ш., 423330
Тел. (885592) 7-24-83, факс (885592) 7-23-85
mailto:adm@aznakay.gov.tatarstan.ruE-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. (885592) 7-24-83, факс (885592) 7-23-85
mailto:aznakay@tatar.ruE-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» сентябрь 2022 ел №282

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге торак пункты территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2022 елның 11 октябрендә 18.00 сәгатькә гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Азнакай ш., Азнакай ур., 2а/1 йорт янында.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Азнакай шәһәре" муниципаль берәмлеге торак пункты территориясенең шушы өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыру өчен территориянең бер өлеше чикләрен түбәндәге территорияләр чикләрендә расларга:

- Азнакай урамы 2а/1 йорттан 72 йортка кадәр торак йортлар.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе өлешендә - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 03 октябреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре башкарма комитетында гражданнар җыенын хәл итүгә чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын түбәндәге адрес буенча оештырырга: Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 14 йорт;

- сайлау хокукына ия, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Азнакай шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясендә Азнакай урамы 2а/1 йорттан 72 йорт буенча яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Азнакай шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешенең Азнакай урамы 2а/1 йорттан 72 йорт буенча яшәүче халыкны массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"Сез, 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы студентларыннан кала һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару буенча үзара салым кертүгә ризамы:

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең Азнакай урамы 2а/1 йорттан 72 йорт буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (юлны асфальт-бетон белән каплау, төяү, ташу, асфальт-бетон салу, төзелеш эшләре өчен түләү).".

« РИЗА» "КАРШЫ"

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 2 көн эчендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык М.З. Шәйдуллин